**РЕШЕНИЕ**
КАЗАНСКОЙ
ГОРОДСКОЙ ДУМЫ

КАЗАН ШӘҺӘРЕ
ДУМАСЫ
**КАРАРЫ**

26.02.2026 г.Казань № 2-6

**Казан шәһәре Мэрының**
**2025 елдагы эшчәнлеге турында хисап**

Казан шәһәре Мэры И.Р.Метшинның Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә тәкъдим ителгән 2025 елдагы эшчәнлеге турында хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, Казан шәһәре Думасы шәһәр Мэрының Россия Федерациясе Конституциясе, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы законы нигезендә эш итүен билгеләп үтә.

Югарыда язылганнардан чыгып, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставындагы шәһәр Мэрының шәһәр халкы һәм Казан шәһәре Думасы контролендә торуы һәм алар каршында хисап тотарга тиешлеге хакындагы нигезләмәләрен үтәп, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Мэрының 2025 елда эшчәнлеге турында хисапны расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Казан шәһәре Башкарма комитетына (Р.Г.Гафаров) шәһәр Мэры хисабы хакында фикер алышканда әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне үтәү буенча чаралар планын төзергә һәм расларга һәм мәгълүматны депутатларга җиткерергә.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2026 елның 26 февралендәге
2-6 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Мэрының**
**2025 елдагы эшчәнлеге турында хисап**

Казан шәһәре Мэры эшчәнлеге турындагы хисап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставындагы муниципаль берәмлек Башлыгының шәһәр халкы һәм Казан шәһәре Думасы контролендә торуы һәм алар каршында хисап тотарга тиешлеге турындагы 34 статья нигезләмәләренә таянып бирелә.

Шәһәр Мэры тарафыннан үз вәкаләтләрен башкаруның хокукый нигезе булып Россия Федерациясе Конституциясе, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы законы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Казан шәһәре Думасы регламенты һәм карарлары, шулай ук муниципаль берәмлекнең югары вазифаи заты эшчәнлегенә кагылышлы башка хокукый актлар тора.

Шәһәр Уставында билгеләнгән статус буенча шәһәр Мэры Казан шәһәре җирле үзидарәсе мөстәкыйльлегенең гаранты булып тора һәм, муниципаль берәмлекнең иң югары вазифаи заты буларак, шәһәрнең бюджет сәясәтен формалаштыра, шәһәр белән идарә итү системасын камилләштерү юнәлешләрен билгели.

**2025 елда эшчәнлекнең төп нәтиҗәләре һәм**
**2026 елга перспективалы планнар**

2025 елда, санкцияләргә һәм тышкы сәяси басымга карамастан, Казан үсеш темпларын һәм шәһәр халкы өчен дә, инвесторлар өчен дә, шәһәр кунаклары өчен дә җәлеп итүчәнлеген саклап кала алды.

**Икътисад**

2025 елда **тулаем территориаль продукт** күләме бәяләү буенча 1,9 триллион сум тәшкил итте.

**Сәнәгать җитештерүе индексы** 103,6 процентны тәшкил итте.

11 ай эчендә үзебездә җитештереп озатылган товар күләме 817 млрд сумны тәшкил итте һәм 12 % үсеш күрсәтте.

**«Казаноргсинтез»да** узган ел база полимерлары өчен катализаторлар фабрикасын төзүгә старт бирелде, ул СИБУРга лаборатор эшләнмәләрдән алып синтетик материалларны сәнәгый җитештерүгә кадәр инновацияләрнең тулы циклын булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

2025 елның декабрендә 250 МВт куәтле яңа пар-газ җайланмасында эшләтеп җибәрү эшләренең беренче этабы тәмамланды. Ул предприятиенең икенчел энергия ресурсларын яндыру нигезендә электр энергиясен алу буенча үз ихтыяҗлары өчен куәтләр булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

**Казан вертолет заводында** «Ростех» предприятиеләре өчен генә түгел, ә сәнәгатьнең төрле тармакларына караган башка заводлар өчен дә киң профильле эшчеләр әзерләү үзәге үз эшен дәвам итте.

2025 елда заводта заманча роботлаштырылган станоклар белән җиһазландырылган механик эшкәртү производствосы ачылды. Бу винт канатлы машиналар төзүнең тулы циклын булдырырга һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга мөмкинлек бирде.

2025 елда **«Казанкомпрессормаш»** территориясендә нефть-газ комплексы өчен насос системалары җитештерү цехы төзелде, аны 2026 ел уртасында эшләтеп җибәрү планлаштырыла, бу базардан киткән дөнья брендларын алыштырып, ел саен 300 гә якын насос системасын җитештерергә мөмкинлек бирәчәк.

Казан авиация заводының импортны алыштыручы Ту-214 очкычы һәм яңартылган фюзеляж, көч җайланмасы һәм борт системасы булган, Россия двигателендә эшләүче «Ансат» вертолеты беренче очышларын башкардылар.

2025 елның ун аенда эре һәм урта предприятиеләр буенча шәһәрдә уртача хезмәт хакы 17 процентка артты һәм 106 мең сумнан артып китте.

Казан миллионлы шәһәрләр арасында 9 ай нәтиҗәләре буенча хезмәт хакы күләме буенча үз позицияләрен ныгытты, 2024 елдагы 3 нче урыннан 2 нче урынга (Екатеринбургтан соң) күчте.

Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе 0,19 % тәшкил итте.

1 289 кеше эшсез буларак теркәлгән, шул ук вакытта 12 мең вакансия бар, ягъни 1 эшсез кешегә 10 эш урыны туры килә.

Төзелешкә һәм заводка белгечләр кирәк, транспортчылар, сәүдә һәм җәмәгать туклануы хезмәткәрләре, укытучылар, табиблар һәм медицина хезмәткәрләренә сорау тотрыклы рәвештә зур.

Бәяләүләр буенча, ваклап сату әйләнеше 1 триллион сумнан артып китәчәк, үсеш – 2 %.

Шәһәрнең 14 авыл хуҗалыгы ярминкәсендә яз һәм көз айларында 1,3 млрд сумнан артык бәягә продукция сатылды.

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов ярдәме белән 6 ярминкә мәйданчыгы яңартылды һәм тагын 2 яңа мәйданчык төзелде, шуларның берсе, күпсанлы үтенечләр буенча, «Салават Күпере»ндә.

**Инвестицияләр**

2025 елның 9 аенда шәһәр икътисадына төп капиталга 301 млрд сум күләмендә инвестицияләр җәлеп ителде.

Тормышка ашырылган проектлар арасында түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк:

- «Химград» технополисын киңәйтү *(инвестицияләр күләме – 188 млн сум)*;
- Кремль яр буенда «Кайт» гастрономия комплексы *(1,1 млрд сум)*;
- Мәскәү базарындагы 387 сәүдә урынын реконструкцияләү *(1,5 млрд сум).*

Инвестиция советы кысаларында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов тарафыннан хупланган проектлар арасында түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк:

- «Татарстан Республикасының пилотсыз авиация системалары үзәге» технопаркы *(инвестицияләр күләме – 1,7 млрд сум)*;
- Киров дамбасы янында күпфункцияле комплекс *(7 млрд сумнан артык).*

Юдино торак массивында урнашкан, терлекчелектә сәнәгать генетикасын үстерүгә юнәлтелгән «ГенБиоТех» агробиотехнопаркы перспективалы проект булып тора *(1,25 млрд сум)*.

2025 елда 200 гектардан артык мәйданда инвестиция күләме 106 млрд сум булган «Төньяк капка» сәнәгать паркын төзү проекты башланып китте.

**Кече һәм урта бизнес**

Кече һәм урта бизнес Казан икътисадында төп роль уйнауны дәвам итә. Аның өлеше шәһәрнең тулаем территориаль продуктының 42,5 процентын тәшкил итә һәм бу өлкәдә шәһәрнең эшли торган халкының өчтән бер өлеше мәшгуль.

Кече һәм урта бизнес субъектларыннан шәһәр казнасына салым керемнәре 43 процентка артты һәм 13 млрд сумнан артып китте.

2025 елда Казанда 86 меңнән артык кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты үз эшчәнлеген алып барды.

2025 елның 9 ае эчендә кече предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы 49 мең сумга җитте, бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 25 процентка күбрәк.

Кече предприятиеләр әйләнеше 842 млрд сум тәшкил итте.

Казанның үзмәшгульләр саны да бер ел эчендә 33 меңгә артты һәм аларның саны 168 мең кешедән артып китте.

Предприятиеләрнең Республика маркетинг үзәге белән хезмәттәшлеге мөһим юнәлеш булып торды. 2025 елда Казанның 2 635 тәэминатчысы 200 миллиард сумга якын керем алды.

Импортны алыштыру системасы саллы ярдәм күрсәтә. Аның каталогында инде 480 меңнән артык товар һәм хезмәт урын алган һәм аларның яртысын Татарстан һәм Казан эшмәкәрләре тәкъдим итә.

Казанда маркетплейслар аша продукция сата торган эшмәкәрләр саны сизелерлек артты. 2025 ел нәтиҗәләре буенча аларның саны 27 меңнән артып китте.

Сәнәгать парклары эшмәкәрлеккә ярдәм итү өчен нәтиҗәле ресурска әверелде. Казанда алар 7 әү – бу 640 тан артык резидент һәм 12 меңгә якын эш урыны дигән сүз.

2025 елның 9 аенда алар тарафыннан төяп җибәрелгән продукция күләме 91 млрд сумнан артып китте, консолидацияләнгән бюджетка салым түләүләре күләме 11 млрд сумга якынлашты.

Ел дәвамында 1 500 дән артык предприятие гомуми суммасы якынча 15 млрд сум булган федераль һәм республика финанс программаларыннан файдаланды.

Шәһәр эшмәкәрләргә нәтиҗәле ярдәм чараларын тәкъдим итүне дәвам итә: җәйге верандаларны бушлай урнаштыру, түләүле парковка урыннарын киметү, вак тәртип бозулар өчен штраф салмау эшмәкәрләргә 83 млн сумнан артык акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирде, «Аренда каникуллары» ташламалы программасы үз эшен дәвам итә.

**Бюджет**

2025 елда шәһәр бюджеты үтәлеше керемнәр буенча 62,3 млрд сум тәшкил итте, 2024 елга карата керем 7,2 процентка үсте (2024 елда – 58,1 млрд сум). Шул ук вакытта салым һәм салым булмаган керемнәр, 14,2 процентка үсеп, 38,0 млрд сум тәшкил итте (2024 елда – 33,2 млрд сум).

2025 елда бюджетның чыгым өлешенең үтәлеше 64,3 млрд сум тәшкил итте, бу 2024 ел дәрәҗәсеннән 18,8 процентка югарырак (2024 елда –

54,1 млрд сум).

Чыгымнарның иң зур өлеше – 75 %, гадәттәгечә, социаль-мәдәни өлкәгә туры килә (48,1 млрд сум).

Шәһәр бюджетының гомуми кереме күләмендә өстенлекле урынны салым керемнәре алып тора – 51,5 % (32,1 млрд сум). Физик затлар кеременә салына торган салым, гадиләштерелгән салым системасы һәм җир салымы салым керемнәренең төп өлешен тәшкил итә.

Хисап мәгълүматларына караганда, Казан территориясеннән 2025 елда 376,7 млрд сум салым җыеп алынган, бу 2024 ел дәрәҗәсеннән 26,5 млрд сумга күбрәк (+8%). Шул ук вакытта шәһәр бюджетына 32,1 млрд сум салым кергән (гомуми сумманың 8,5 проценты).

Республика бюджетыннан, шулай ук милли проектлар буенча федераль акчаларны исәпкә алып, юллар, җәмәгать урыннары һәм ишегаллары, мәктәпләр һәм балалар бакчалары, хастаханәләр һәм сырхауханәләр, мәдәният йортлары һәм китапханәләр төзү һәм ремонтлау, күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау финансланды.

**Төзекләндерү**

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов инициативасы белән республикада һәм аның башкаласында гамәлгә ашырыла торган мөһим проектларның берсе – «Безнең ишегалды» программасы.

Программа эшләү барышында гомуми мәйданы 3,6 млн кв.м булган 2 754 ишегалды төзекләндерелде.

600 меңнән артык кешенең яшәү сыйфаты яхшыртылды.

2025 елда 466 күпфатирлы йорт территорияләре төзекләндерелде.

Агымдагы елда 420 ишегалдын төзекләндерү планлаштырыла һәм 2027 елда тагын 280 ишегалдын төзекләндерүгә ихтыяҗ кала.

**Җәмәгать урыннары**

Паркларны һәм скверларны төзекләндерү программасы дәвам итте.

Уникаль «Елмай» балалар паркы булдырылды, Казан шәһәренең үзәк мәдәният һәм ял паркы, Түбән Кабан күле яр буе, «Аккош күле» урман паркы, Горки-Әмәт урманы, «Черек күл» паркы һәм шәһәр халкының дистәләгән башка ял итү урыннары төзекләндерелде.

Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясендә эшләүче яшь креатив команда, киңлекләрне заманча мәгънәләр һәм актуаль вакыйгалар белән баетып, үз эшен дәвам итте.

Хисап елында федераль проект кысаларында Зур һәм Кече Акчарлак күлләре, Серов урамындагы бульвар, шулай ук шәһәр халкы һәм туристлар өчен әһәмиятле булган «Зилант» скверы территорияләрен төзекләндерү эшләре дәвам итте.

Республика бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына тагын 5 объектта эшләр башкарылды:

- Г.Камал театры янындагы балалар мәйданчыгы төзекләндерелде;

- Казансу елгасында һәлак булган сугышчылар хөрмәтенә төзелгән гыйбадәтханә-һәйкәл территориясе төзекләндерелде;

- Җиңү паркында махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәйкәл куелачак урынга мемориаль таш салынды;

- фронтовик шагыйрь Фатыйх Кәримгә һәйкәл куелды һәм Декабристлар урамындагы «Яшьләр» скверының бер өлеше төзекләндерелде;

- «Салават күпере»ндә, территориясен төзекләндерү эшләре дә башкарылып, генерал Мәхмүт Гәрәевкә бюст куелды.

**Төзелеш**

Казан – актив үсештәге шәһәр. 2005 елдан алып Казан халкы 214 мең кешегә артты, соңгы 20 елда шәһәрдә 380 меңнән артык бала тууы теркәлде.

Хисап чорында Казанда 1 310 565 кв.м торак файдалануга тапшырылды, шул исәптән 92 меңе – Социаль ипотека программасы буенча.

Россиянең эре шәһәрләре арасындагы социаль-икътисади хәлне бәяләү рейтингы буенча Казан хисап елының беренче тугыз аенда торак төзелеше өлкәсендә үз позициясен яхшыртты, 2024 елда 4 нче урыннан 2 нче урынга күтәрелде.

Шәһәрдә Алафузов фабрикасы, «Сантехприбор» заводы һәм Родина урамы территорияләре кебек сәнәгать зоналары актив рәвештә яңартыла.

Кайчандыр депрессив булган бу мәйданчыкларда бүген барлык кирәкле инфраструктурасы булган заманча торак комплекслары төзелә.

Шәһәребез төрле илләрнең әйдәп баручы архитекторларында чынлап торып кызыксыну уята. Бездә уза торган зур чаралар диалог өчен мөһим мәйданчыклар булып тора:

- «Казаныш» бөтенроссия архитектура-төзелеш форумы, ул 2025 елда БРИКС+ илләре шәһәрләренең 39 баш архитекторын җыйды һәм соңгы өч ел эчендә дөньяда архитектура һәм шәһәр төзелеше буенча иң эре форумга әверелде;

- «Диалоглар» конференциясе, анда конкрет кейслар, инновацион алымнар карап тикшерелде һәм экспертлар арасында хезмәттәшлек оештырылды.

Мондый очрашулар һәм диалогларның төп нәтиҗәсе – Казанда тормышка ашырыла башлаган яңа заманча урбанистик проектлар.

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов безнең тарафтан эшләнгән «Казан – судагы шәһәр» концепциясен хуплады. Аны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә Казан башкала халкы һәм кунаклары өчен су капкаларын ачачак, шәһәрнең яңа киләчәген символлаштырып, табигать һәм урбанистика гармонияле бердәмлеккә ирешәчәк.

«Яңа порт» территориясендә 287 га мәйданда кластер төзү эше башланды. Планда – 42 мең кешегә исәпләнгән 1,3 млн кв.м торакны, 72 га мәйданда яшел зоналары булган социаль инфраструктура объектларын һәм җәмәгать урыннарын, судан саклау корылмаларын һәм 12 км озынлыктагы яр буен файдалануга тапшыру.

Локомотив ярымутравын үстерү концепциясе кысаларында төп шәһәр маринасын төзү, Иделдә ел буена спортның су төрләре белән шөгыльләнү мөмкинлеге булган иң эре су-туристлык кластерын булдыру планлаштырыла.

Су-туристлык кластерын гамәлгә ашыруның гомуми социаль-икътисади нәтиҗәсе – туристлар агымының артуы, эш урыннары булдыру һәм өстәмә салымнар (10 елда 30 млрд сумга кадәр).

**Ләм кырлары** территориясен экологик яктан реновацияләү планлаштырыла. Фәнни-эшлекле кластер, медицина, концерт һәм спорт объектлары урнаштырылачак, шәһәр мариналары челтәренә интеграцияләнәчәк «Зур Идел» мега-паркы концепциясе эшләнә, аның мәйданы 208 гектардан артык булачак.

Республика Хөкүмәте, шулай ук туган шәһәре тарихына битараф булмаган инвесторлар белән берлектә без Казанның тарихи үзәген саклап калу эшен дәвам итәбез.

Республика Рәисе каршындагы шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме тарафыннан 87 объектның концепциясе карап тикшерелде, шул исәптән аларның иң әһәмиятлеләре:

- Үзәк универмаг бинасын реконструкцияләү;

- «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең уку-лаборатория корпусы;

- Киров дамбасында кунакханә комплексы концепциясе;

- Казан шәһәренең Үзәк мәдәният һәм ял паркы буйлап Подлужная урамына кадәр төшү территориясен комплекслы төзекләндерү;

- Г.Камал исемендәге театр;
- Кытай Халык Республикасының Подлужная урамындагы консуллык үзәге;
- Островский урамындагы яшь тамашачы театры бинасын реконструкцияләү;
- Алинә Заһитованың фигуралы шуу үзәге.

**Юллар**

Хисап елында гомуми мәйданы 2 млн кв.метрдан артык булган 250 юл участогы ремонтланды, шулай ук К.Нәҗми урамындагы Болак елгасы аша салынган күпердә һәм Достоевский урамындагы юлүткәргечтә ремонт эшләре башкарылды.

Краснококшайский урамында җәяүлеләр өчен җир өсте кичүе төзелде, Х.Мәүлетов урамында җир асты кичүе төзелеше тәмамланды.

Җиңү проспектыннан Оренбург трактындагы шәһәрдән чыгу юнәлешендәге юлүткәргечкә керү юлы киңәйтелде.

Юл өслегенең 90 проценттан артыгы тузган торак массивларында рекордлы күләмдә юл эшләре башкарылды – гомуми озынлыгы 19 километрдан артык булган 102 урамга ремонт ясалды, 1 меңнән артык энергия саклаучы яктырткыч куелды.

**Юлларны карап тоту**

Шәһәрдә төзелгән юлларны норматив хәлдә тотарга – юл билгеләрен, куркынычсызлык киртәләрен вакытында ремонтларга, урнаштырырга һәм чистартырга, чүп-чарны, карны һәм бозны җыештырырга кирәк.

2025 елда без, мөмкинлекләр табып, юлларны карап тоту өлкәсен финанслауны (2 тапкырга диярлек) арттыра алдык. Әлеге ярдәм чарасы предприятиеләргә матди-техник тәэмин ителешне яхшыртырга, юл хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәт хакларын (20 дән 25 процентка кадәр) күтәрергә мөмкинлек бирде, бу үз чиратында өстәмә кадрлар җәлеп итәргә ярдәм итте.

Воровский урамында «Шәһәрне төзекләндерү» муниципаль унитар предприятиесенең яңа базасын төзү зур адым булды, ул барлык заманча таләпләргә җавап бирә, анда техниканы ремонтлау һәм карап тоту өчен генә түгел, ә, беренче чиратта, кешеләрнең үзләре өчен дә технологик, уңайлы киңлекләр булдырылды.

Татарстан Республикасы җитәкчелеге ярдәме белән 2025 елда муниципаль предприятиеләр өчен тротуарларны һәм җәяүлеләр зоналарын карап тоту өчен 8 вакуумлы коммуналь машина сатып алынды.

Чистарту процессларын реинжинирингләу, цифрлы технологияләр кертү буенча күләмле эш башкарылды, бу төп заказчыдан алып машина йөртүчегә һәм юл эшчесенә кадәр барлык дәрәҗәләрне дә колачлады.

Техниканы һәм персоналны әзерләү һәм эш урыннарына чыгару процессы оптимальләштерелде, электрон юл кәгазьләре системасы кертелде, бу машина йөртүчеләрнең һәм техниканың чыгуын тизләтергә мөмкинлек бирде.

Хезмәткәрләрнең сәламәтлеген контрольдә тоту өчен телемедицина системасы кертелде.

«Шәһәр мониторы» һәм «СитиСофт» цифрлы системалары маршрутларны күрергә генә түгел, ә җентекләп, реаль вакыт режимында юлларны карап тоту сыйфатындагы тайпылышларны теркәргә һәм хезмәтләрнең эшен тиз арада төзәтергә мөмкинлек бирде.

Кар эретү пунктларына электрон талоннар системасы кертелде.

**Торак-коммуналь хуҗалык**

Хисап елында 4,0 млрд сумнан артык гомуми суммага 224 йортка капиталь ремонт ясалды, 141 йортта 457 лифт алыштырылды.

2025 елда инженерлык челтәрләрендә һәм корылмаларында 5,53 млрд сумлык, шул исәптән коммуналь инфраструктураны модернизацияләүнең республика программасы буенча – 1,57 млрд сумлык, предприятиеләрнең инвестиция программалары буенча – барлыгы 4,53 млрд сумлык эшләр башкарылды.

Көн саен Казанда 1 600 тонна каты коммуналь калдыклар хасил була һәм полигонга чыгарыла.

2018 елдан башлап Казанда калдыкларны аерым җыю гамәлгә ашырыла. Контейнер мәйданчыклары пыяла, кәгазь һәм пластик өчен махсус контейнерлар белән җиһазландырылган. Кече һәм урта бизнеска икенчел чимал җыю һәм эшкәртү объектларын урнаштыру өчен җир участоклары бирү рәвешендә ярдәм күрсәтелә.

Халык белән киң күләмле белем бирү һәм аңлату эшләре алып барыла, бу аларга калдыклар белән җаваплы эш итүнең тотрыклы гадәтләрен үстерергә ярдәм итә.

**Транспорт**

Шәһәребездә яшәүчеләрнең өчтән бере даими рәвештә җәмәгать транспортыннан файдалана. Бу эш көннәрендә уртача 750 меңнән артык сәфәр.

Узган ел «НефАЗ» маркалы зур сыйдырышлы 30 газ автобусы сатып алынды.

2026 елда, 10 еллык эксплуатация вакыты үтү сәбәпле, 2016 елда сатып алынган 106 автобусны алыштырырга кирәк булачак.

Җир өсте электр транспортының контакт-кабель челтәренең, трамвай юлларының һәм тарту подстанцияләренең нык тузуы йөртү куркынычсызлыгына тәэсир итә һәм маршрутлар буенча хәрәкәт тизлегендә чагылыш таба.

2025 елда машина йөртүчеләр саны нибары 75 кешегә генә арткан, машина йөртүчеләргә кытлык элеккечә югары һәм 30 % тәшкил итә (583 кеше).

Соңгы елларда юл челтәрен үстерү өстенлекле юнәлешләрнең берсе булды.

Йөзләгән урам-юл челтәре объектлары ремонтланды һәм төзелде, федераль трассалар, күперләр һәм юлүткәргечләр реконструкцияләнде.

Бүгенге көндә шәһәрдә теркәлгән автомобильләр саны 497 меңнән артып китә һәм ел саен уртача 10 меңгә арта, автомобильләшү дәрәҗәсе – 1 мең кешегә 374 автомобиль туры килә.

Шәхси машинага караганда җәмәгать транспортында йөрүне уңайлырак һәм тизрәк итә торган шартлар тудыру буенча эшне дәвам итәргә кирәк.

**Мәгариф**

2025 елда яңа милли проектларны, шул исәптән мәгариф өлкәсендәге программаларны («Яшьләр һәм балалар», «Гаилә») гамәлгә ашыру дәвам итте.

«Яшьләр һәм балалар» милли проекты кысаларында яңа уку елында «Лето» торак комплексында физика-математика лицее үз ишекләрен ачты.

14 мәктәптә 686 млн сумлык ремонт эшләре башкарылды, шуларның 12 сендә азык-төлек блоклары яңартылды. Мәктәп рестораннарының сыйдырышлыгы 291 урынга артты.

«33 нче Хәрби шәһәрчек» торак комплексында 220 урынга исәпләнгән балалар бакчасы төзелеше һәм «Гаилә» милли проекты кысаларында 2 балалар бакчасында ремонт эшләре төгәлләнде.

Соңгы 20 ел эчендә барлыгы 42 мәктәп төзелде, шулай ук 144 балалар бакчасы төзеп тапшырылды һәм 89 ы ремонтланды.

Без укуда һәм олимпиада хәрәкәтендә яхшы нәтиҗәләр күрсәткән сәләтле балаларыбыз белән горурланабыз.

Чыгарылыш сыйныф укучыларының 20 проценты мәктәпне медальләр белән тәмамлады.

160 чыгарылыш сыйныф укучыбыз йөз балл җыйды, шуларның 7 се берьюлы ике фәннән бу максатка иреште.

2025 елда Казан бердәм дәүләт имтиханында барлык фәннәрдән дә Россия буенча уртача күрсәткечне узып китте.

Казан укучылары бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында 162 призлы урын яулады – бу Татарстанның барлык медальләренең 61 проценты.

Бүген шәһәрдәге 17 300 мәктәп укучысы төрле олимпиадаларда катнаша. Мең кешегә исәпләгәндә Россиядә предмет олимпиадаларында җиңүчеләр саны буенча без 2 нче урында торабыз. Казан укучылары халыкара дәрәҗәдәге олимпиадаларда 6 алтын һәм 3 көмеш медаль яуладылар.

2025 елда бердәм дәүләт имтиханында 100 балл җыйган 82 чыгарылыш сыйныф укучысы (59,4 %) республикабызның югары уку йортларында белем алуларын дәвам иттеләр.

Укытучы һөнәренең абруен күтәрү өстендә эш дәвам итә. 2025 елда Россиянең 55 һәм чит илләрнең өч югары уку йортында белем алган 460 яшь педагог эшкә урнашты.

Яшь педагогларның эштә урнашып калу күрсәткече уртача 75 %, яшь педагоглар өлеше – 29 %. Казанның һәр өченче укытучысы 35 яшьтән яшьрәк, бу Россия буенча уртача күрсәткечтән югарырак.

Биш ел эчендә генә дә илнең башка төбәкләреннән 800 педагог Казанда даими эш тапкан.

Подлужная урамында Мәгариф хезмәткәрләре йорты төзелеше һәм укытучылар скверын төзекләндерү эшләре тәмамланып килә. Яңа объект педагогларны укыту, тәҗрибә уртаклашу һәм яңа идеяләр уйлап табу өчен уникаль мәйданчыкка әвереләчәк.

**Мәдәният**

Казан традицион рәвештә күпкырлы мәдәният белән ассоциацияләнә. Ел саен безнең башкаланың концерт залларында да, җәмәгать урыннарында да аншлаг белән камера музыкасы концертларыннан алып рок-фестивальләргә кадәр меңләгән мәдәни чаралар уза.

2025 елда узган чараларның гомуми саны – 21 000, аларны 22 млн кеше карады.

2025 елның 29 июнендә «Казан» гаилә үзәге янында Россиянең иң зур VK Fest музыка фестивале узды, аны карарга 20 меңгә якын кунак җыелды.

2025 елның 21-26 августында Казанда беренче тапкыр «Новая волна – 2025» халыкара музыка фестивале узды һәм елның төп мәдәни вакыйгаларының берсенә әйләнде.

«Игелекле Дулкын» бөтенроссия балалар иҗаты хәйрия фестивале узды.

Бүгенге көндә Казандагы мәдәният учреждениеләренең 90 проценты ремонтланды яки яңа биналарга күченде.

**Сәламәтлек саклау**

Соңгы 20 елда тармакны модернизацияләүгә 70 млрд сумнан артык акча тотылды.

13 яңа хастаханә, 16 яңа поликлиника бинасы, 7 югары технологияле медицина үзәге төзелде.

72 сәламәтлек саклау объектына капиталь ремонт ясалды.

2025 хисап елында «Салават Күпере» торак комплексында 60 меңнән артык кешегә исәпләнгән шәһәрдәге иң зур поликлиника үзенең беренче пациентларын кабул итте, бу республиканың аерым бер район халкы санына тигез.

Вишневка торак массивында гомуми практика табибы һәм педиатр үзәге төзелде, «Весна» торак комплексында өлкәннәр өчен, ә «Волжские просторы» торак комплексында балалар өчен поликлиника ачылды.

18 нче хастаханәнең кабул итү-диагностика бүлеген төзү эшләре дәвам итә.

**Спорт**

Хисап елында Казанда халыкара, федераль һәм төбәк дәрәҗәсендәге 532 ярыш үткәрелде, аларда 150 мең спортчы катнашты.

Бүгенге көндә шәһәр халкының 68 процентган артыгы спортны яшәү рәвеше итеп сайлады.

**Инклюзия**

Казан Мэриясенең өстенлекле бурычларыннан берсе – сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләрне кайгырту.

Шәһәрдә 7 инклюзив үзәк һәм 5 күнекмә фатиры эшләп килә, алар мөмкинлекләре чикле 2 меңнән артык баланы һәм өлкәннәрне һәм барлык 7 нозология буенча инвалидларны колачлый.

2025 елда беренче тапкыр бизнес-берләшмәләр һәм Президент грантлары фонды ярдәмендә шәһәрдә беренче «Вместе» инклюзив үзәге ачылды. Ул инклюзив җәмгыятьне үстерүдә бергәләп эшләү өчен педагогларны җыеп, Казан

шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе һәм «Игелекле Казан» проекты тырышлыкларын берләштерә торган мөһим мәйданчыкка әверелде.

2025 елда «Тылсым» инклюзив үзәгендә сабыйлар өчен кыска вакытка калу төркеме, «ЛУЧ» үзәгендә өлкән яшьтәге инвалидлар өчен төркем, Калинин урамында балта остаханәсе һәм «Игелекле Казан» коворкингында инклюзив типография ачылды.

Шәһәрдә үсешләрендә тайпылышлары булган балалар өчен 54 база мәктәбе бар, шул ук вакытта шәһәрдәге 174 мәктәпнең һәркайсы укуга үзенчәлекле бала кабул итәргә әзер.

2024 елда 33 номерлы балалар бакчасы Россиянең иң яхшы инклюзив балалар бакчасы булды, ә 2025 елда 78 номерлы лицей Россиянең иң яхшы инклюзив мәктәбе дип танылды.

«Балалар академиясе» балалар иҗаты үзәгенең филиалы ачылды. Ел дәвамында ул 4 200 баланы, шул исәптән үсеш үзенчәлекләре булган балаларны да кабул итә алачак. Ә ата-аналар өчен психологик ярдәм клубы оештырылды, пространство концепциясендә балаларга гына түгел, ә аларның ата-аналарына да ярдәм итү каралган.

Тиздән «Ярдәм» тернәкләндерү комплексы үз ишекләрен ачачак, анда якын арада бизәү эшләре һәм махсус җиһазлар урнаштыру башланачак, шуннан соң ул ел саен 15 600 кешегә хезмәт күрсәтә алачак.

2013 елдан эшләп килүче «Ярдәм» үзәге 23 меңнән артык кешегә ярдәм күрсәтте.

Серов урамында инклюзив бульварны төзекләндерү кысаларында халыкның хәрәкәте чикле төркемнәре өчен велосипед юлының кече бозрасы эшләнде. Шулай ук СИБУР ярдәме белән әлеге категория гражданнар өчен велосипед прокаты пункты булган экопавильон урнаштырылды.

**Цифрлаштыру**

Хисап елында шәһәрнең цифрлы игезәге концепциясе тәкъдим ителде. Реаль вакытта шәһәр процессларын чагылдырып торучы, мәгълүматларны даими яңартып торучы шәһәрнең бердәм виртуаль моделе инфраструктураны үстерүне планлаштырырга һәм актуаль мәгълүмат нигезендә карарлар кабул итәргә мөмкинлек бирә.

«Сити Софт» контроль системасы ярдәмендә юлларның һәм яктыртуның торышын күзәтергә, урамнарны җыештыру һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү белән идарә итәргә була.

Ә Казанның транспорт моделе акыллы светофорлардан, трафикны исәпләү камераларыннан һәм юл-транспорт һәлакәтләрен анализлаудан алынган мәгълүматларны берләштерә, бу исә хәрәкәтне нәтиҗәле оештырырга һәм аварияләрне киметергә мөмкинлек бирә.

Казан территориясендә яшәүчеләр һәм туристлар уңайлылыгы өчен паркларда, скверларда, яр буйларында, рестораннарда һәм кунакханәләрдә, шулай ук иң популяр туристик локациядә – Бауман урамында Wi-Fi га бушлай тоташу проекты эшләтеп җибәрелде.

Казанның тышкы күренешен яхшырту өчен элмә элемтә линияләрен җир асты коммуникацияләренә күчерү проекты гамәлгә ашырыла. Элек эшләп килгән 2 527 км элмә линияләрнең 419 километрын җир астына күчерәсе калды.

Видеокүзәтү системаларын модернизацияләү кысаларында 463 мәгариф учреждениесендә, күрсәтү төгәллеген арттырып, 7 334 видеокамера алыштырыла, бу видеоагымнарның сыйфатын һәм аларның детальләшүен арттырачак.

Агымдагы елда «Ак Барс» Банкы гавами акционерлык җәмгыяте белән берлектә «Бердәм балалар картасы»н булдыру планлаштырыла, әлеге карта мәктәпкә керү ачкычы булачак, шулай ук балалар бу карта ярдәмендә мәктәптә туклану, шәһәр җәмәгать транспортында йөрү өчен һәм теләсә кайсы касса терминалында – кибеттә, кафеда түли алачак, асылда ата-аналар контроле чарасы да булачак.

Цифрлы технологияләр тиз үсә торган чорда, кызганычка каршы, моның кире ягы да ачыграк күренә – төп куркынычларның берсенә әверелгән **киберҗинаятьчелек үсеше** күзәтелә.

«Минем Казан» порталында аккаунтларны саклау буенча инструкцияләр һәм гаджетларны куркынычсыз куллану буенча киңәшләр булган киберкуркынычсызлык буенча махсуслаштырылган сайт эшли башлады.

Ел дәвамында Казан Мэриясенең актив хезмәткәрләреннән торган цифрлы куркынычсызлык командасы мәктәп укучылары һәм студентлар өчен (дәресләр, презентацияләр, квизлар), шәһәр халкы өчен (ачык очрашулар һәм ата-аналар җыелышы) чаралар сериясен, шулай ук «Яшәү яме» проекты кысаларында ярдәмгә иң мохтаҗ төркем – пенсионерлар өчен аерым блок дәресләр үткәрәчәк.

**Туризмны үстерү**

2025 елда Казан, Russian Event Awards Халыкара Премиясенең «Вакыйгалы туризм өчен иң яхшы шәһәр» номинациясендә җиңү яулап, үзенең стратегик курсы буенча зур танылу алды.

Бүләк БРИКС илләре саммитын, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum», «Kazan Digital Week» форумнарын һәм башка зур чараларны уңышлы уздыруда алдынгы федераль һәм халыкара мәйданчык буларак Казан имиджын формалаштыруда күпьеллык эшкә нәтиҗә булды.

Сентябрьдә Казанда 12 илдән (Россия, Беларусь, Казахстан, Үзбәкстан, Бразилия, Һиндстан, Көньяк Африка Республикасы, Кытай, Эфиопия, Иран, Индонезия, Мисыр) 150 яшүсмерне җыйган тарихта беренче БРИКС+ илләре яшүсмерләр фестивале узды. Яшүсмерләр математика һәм информатика буенча беренче халыкара олимпиадада һәм яшьләр сәясәтен һәм мәгарифне үстерү мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәлдә катнашты.

Вакыйгалы стратегия 2025 елда туристлар агымы үсешенә турыдан-туры конвертацияләнде – ул 5,1 миллион кешегә житте, бу алдагы ел күрсәткечләреннән 13 процентка күбрәк.

Төп цифрлы инструмент – бердәм туристлык порталы go.kzn.ru эшләтеп җибәрелде, ул шәһәрнең үзәк витринасына әверелде, порталда кунакларга өч телдә комплекслы мәгълүмат һәм сервислар тәкъдим ителә.

2025 ел календарендә якты проектлар күп булды, һәрберсе Казанны килеп карауга сәбәп иде.

«Россия тәме x Тәмле Казан» гастрономия фестивале 85 мең кунакны җәлеп итте, ә «Төнге велофест» илнең 20 шәһәреннән 4 мең катнашучыны җыйды. Яңа җирле традицияләр дә уңышлы барлыкка килә, мәсәлән, «Әкият» курчак театры янындагы «Бияләй» яңа ел ярминкәсе 16 көн эшләү дәверендә 20 мең кешене кабул итте.

Кунакханәләрдә урнашуга ихтыяҗ арту (кунакханәләрнең уртача йөкләнеше, җәйге чорда 90 процентка кадәр менеп, 60 процентка җиткән иде) кунакханә инфраструктурасын үстерүне стимуллаштыра. Шуңа җавап итеп яңа объектлар ачылды – тарихи үзәктә MUNIB кунакханәсе һәм шәһәр яны зонасында AK BARS Golf&Resort, шулай ук биш йолдызлы Millennium Panorama кунакханәсе төзелде.

Казанның туризм тармагын үстерү перспективалары яңа югары статусларга һәм амбициоз инфраструктура проектларына таяна. Шәһәргә «Ислам дөньясының мәдәни башкаласы – 2026» исемен бирү халыкара мәдәни агымны җәлеп итүдә яңа этап ача.

Кунакларны лаеклы кабул итү һәм яңа җәлеп итү нокталары булдыру өчен масштаблы планнар тормышка ашырыла: зооботаника бакчасын күпфункцияле туристлык кластеры итеп модернизацияләү, аэропортның яңа пассажирлар терминалын төзү һәм Уникаль осталар үзәген булдыру.

Шул рәвешле, Казанда туризм ул хезмәт күрсәтү өлкәсе генә түгел, ә шәһәр икътисадының төп тармагына әйләнде һәм чиктәш секторларның – сәүдә, җәмәгать туклануы, транспорт үсешенә этәргеч булды.

**Ватанны саклаучылар елы**

2025 елда Казанда Ватанны саклаучылар елы билгеләп үтелде.

Шәһәрдә 5 меңнән артык (5 111) чара, акция һәм бәйгеләр узды, Бөек Ватан сугышына, махсус хәрби операция геройларына багышланган һәм Казанның Хезмәт батырлыгы шәһәре булуы уңаеннан күргәзмәләр үткәрелде, музейлар, мемориаль такталар ачылды.

Җиңүнең 80 еллыгы истәлегенә Бөек Ватан сугышы ветераннарына 2025 елда 2 216 юбилей медале тапшырылды, 59 сугыш ветеранына «Казанның Мактаулы гражданины» дигән югары исем бирелде.

«Игелекле Казан» кайнар линия оештырды – бүген аңа махсус хәрби операция белән бәйле сораулар буенча 50 000 нән артык шалтырату килде.

Шәһәр мәктәпләрендә махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән булган 5 мең укучы ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин ителде.

2 мең баланың ата-анасы түләүләрдән азат ителде.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары балалар бакчасына чираттан тыш кабул ителде.

6 меңнән артык транспорт картасы һәм 9 меңгә якын «Батыр» картасы бирелде.

2025 ел башыннан алып мәктәп яны һәм шәһәр яны лагерьларында махсус хәрби операциядә катнашучыларның 2 326 баласы ял итте.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның 4 меңнән артык гаиләсе азык-төлек продуктлары, көнкүреш техникасы, дарулар, торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре өчен түләүдә, торакны ремонтлауда һәм арендага алуда, медицина хезмәтләре өлешендә һәм башка бик күп мәсьәләләр буенча ярдәм алды.

«Нәфис» компаниясенең хәйрия фонды һәлак булганнарның гаиләләренә һәм инвалидлык алган хәрби хәрәкәтләр ветераннарына азык-төлек җыелмалары һәм көнкүреш химиясе җыелмалары бирә. Узган ел Курск өлкәсенә, Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә гуманитар ярдәм белән 5 фура, ә махсус операция башланганнан бирле барлыгы 40 фура җибәрелде.

Волонтерлар инициативасы белән шәһәрдә хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларны тыныч тормышка җайлаштыруга, ветераннарга һәм аларның

гаилә әгъзаларына ярдәм итүгә, алар арасыннан лидерлар һәм остазлар командасын формалаштыруга юнәлдерелгән «Туган» проекты гамәлгә ашырыла.

100 дән артык махсус хәрби операция ветераны, инвалидлык алганнарын да кертеп, спорт объектларында йөзү, теннис, футбол һәм башка спорт төрләре белән шөгыльләнәләр.

Июльдә шәһәрдә беренче тапкыр «Абилимпикс» чемпионаты үтте, монда Россиянең 79 төбәгеннән 259 конкурсант катнашты, августта – следж-хоккей буенча төбәкара «Өчлек турниры», ә сентябрьдә Татарстан Республикасы Рәисе Спорт кубогына финал этабы уңышлы узды.

Махсус хәрби операция башланганнан ук алгы сызыкка бронежилетлар, автомобильләр, кирәк-яраклар, төзелеш материаллары, медикаментлар һәм азык-төлек продуктлары җибәрелә.

Махсус хәрби операция зонасына безнең якташ сугышчыларга 74 гуманитар конвой һәм Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә 86 фура – 1 600 тоннадан артык гуманитар ярдәм җибәрелде.

Казан мәктәпләре бер ел эчендә сугышчыларга 15 млн сумнан артык гуманитар ярдәм җыйды, балалар хат һәм открыткалар, рәсемнәр һәм кул эшләре, догалыклар һәм кесә иконалары, үзләренең иҗади чыгышларының язмаларын җибәрәләр.

Хәрби, гражданлык яки хезмәт бурычын үтәгәндә кыюлык һәм фидакарьлек күрсәткән халкыбызның чын батырлыкларын билгеләп үтү өчен яңа муниципаль бүләкләр – «Казанның Горурлыгы һәм Даны» аерым хөрмәт билгесе һәм «Казан волонтеры» мактау билгесе булдырылды.

Туган мәсьәләләрне – хәрәкәт итү логистикасын оештыру, ягулык-майлау материаллары һәм чимал белән тәэмин итү, иганәчеләр эзләү сорауларын оператив рәвештә хәл итү өчен Казанда Координация советы төзелде.

Сентябрьдә хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан 4 кеше һәм Координация советының 2 вәкиле Казан шәһәре Думасы депутатлары итеп сайланды.

Уртак тырышлык нәтиҗәсендә Казан ирешелгән үсеш темпларын саклап кала алачак һәм республикабыз халкы һәм кунаклары иминлеге хакына яңа уңышларга ирешә алачак.

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**